ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Яруллина, д.7а, с.Малая Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422173

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ярулин ур., 7а йорт, Кече Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422173

тел.(факс): (85563) 3-07-03; e-mail: : Sun.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР
22.11.2018 ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№18

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән «19» ноябрь 2018 елдагы № 921 карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Сон авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесе

М.Ф.Салахов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы,Сон авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 22 ноябре 18№
лы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы,**
**Сон авыл җирлеге гражданнарының**
**үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Сон авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 28.02.2019 вакытка кадәр, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш,

1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр,

аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә яраксыз,

б) хезмәт буенча командировка,

гражданнарга гариза нигезендә бер айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин,

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына муниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгару һәм халыкка җиткерү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы уставында бигеләнгән тәртиптә, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге

буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Сон авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 18 № лы
карарына 2 нче кушымта

Сон авыл җирлеге
(*муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_______________________________________________________________
Адрес: _______________________________________________________

Нигезләмә: Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге 921 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре турында Сезгә 2019 елның 28 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум чараларын тормышка ашыру өчен 400 сум күләмендәге түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы Татарстан Республика НБ бүлеге, БИК 049205001
Сч. № _________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № 40101810800000010001
ИНН 1626008921
КПП 162601001
КБК 60511714030100000180 ОКАТО 92638480
Түләүнең билгеләнеше
Үзара салым
Җитәкче __________________ Сәләхов М.Ф.____________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

_________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне
_________________ сум күләмендә түләү турында № _________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и. _____________________________________________
Адрес:
_______________________________________________________________
Кабул ителде «__» _______________ 201 ел.

__________________________________________
(түләүченең имзасы)